Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге составына керүче
Олы Әшнәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

22 ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 22 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авылы су скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарын төзекләндерү өчен вак таш ташу буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарының юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны чистарту);
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авылы урамнарына энергияне саклый торган лампалар сатып алу;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарының читләреннән чүп үләннәре чабу;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авылларының су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 203 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 144 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 144 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге составына керүче Олы Әшнәк авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип таныргa.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авылы су скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарын төзекләндерү өчен вак таш ташу буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарының юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны чистарту);
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авылы урамнарына энергияне саклый торган лампалар сатып алу;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авыллары урамнарының читләреннән чүп үләннәре чабу;
- Олы Әшнәк, Кече Әшнәк авылларының су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү;

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорты;Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Хөснетдинова Р.Ә.

Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы Хөснетдинова Р.Ә.